ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НОВОТРОИЦК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
КАРАР

08 ноябрь, 2019 ел. № 5

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицкое авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Уставы,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 19 ноябрь көнне 2019 елның сәгать 18.00 Новотроицк авылында урамнары Новая, Новоселов, Молодежная, Солнечная, Придорожная, Луговая, Цветочная, Полевая, Сармановкая, Юбилейная, Автозаводская, Космонавтов, Энергетиков үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 20 ноябрь көнне 2019 елның сәгать 14.00 Новотроицк авылында Березовая, Садовая, Зеленая, Тополиный тыкрыгы, Центральная урамында 23-94 санлы үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 22 ноябрь көнне 2019 елның сәгать 18.00 Новотроицк авылында Ленина, Центральная с д. № 1-22 санлы үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. 21 ноябрь көнне 2019 елның сәгать 18.00 Новотроицк авылында Челнинская, к-с Тукаевский, к-с Жукова үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының дуртенче этабын билгеләргә.
5. Халык җыенын уздыру өчен Новотроицк авыл яшәүчеләрнең исемлеге аерым бүленә, сайлау тәртибе территориаль билге буенча башкарылырга тиеш.
6. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
   «2020 елда яшәү урыны буенча Новотроицк авыл җирлеге Новотроицк авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:
   - юлларны ремонтлау;
   - электроматериаллар сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру;

- 1 нче зиратка хуҗалык инвентаре өчен бина сатып алу һәм урнаштыру;
- аларга ясалма тигезсезлекләр һәм юл билгеләре сатып алу, урнаштыру.
«ӘЙЕ» «ЮК».

7. Халык җыенын беренче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Новотроицк авыл, Ленин урамы, 11 йорт адресы буенча үткәрергә.
8. Халык җыенын икенче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Новотроцк авыл, Үзәк урамы, чиркәү янында.
9. Халык җыенын өченче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Новотроицк авыл, Ленин урамы, 11 йорт адресы буенча үткәрергә.
10. Халык җыенын дуртенче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Новотроицк авыл, Ленин урамы, 11 йорт адресы буенча үткәрергә.
11. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләргә.
12. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
11. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Баш
Новотроицк авыл җирлеге башлыгы Р. Р. Волкова